**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"29" март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы "2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

"2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Кышлау авылы күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү));
3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү)."
4) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгынны сүндерү өчен махсуслаштырылган цистерна сатып алу).»

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.